ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 27-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 27-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 23 декабре
№ 141-VII ДС

Проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**«Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

**1 статья**

«Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» 2009 елның 17 июнендәге 19-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 1 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 6, № 9 – 10; 2011, № 5; 2012, № 6 (I өлеш); 2015, № 8 – 9; 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнары җыелмасы, 2017, № 50 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2023, № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 76 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 пунктта «2 өлешенең 1 пунктының һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) түбәндәге эчтәлектәге 5 пунктны өстәргә:
«5) 2026 елның 1 гыйнварыннан әлеге Законның 1 статьясындагы 2 өлешенең 1 пунктын».

**2 статья**

Әлеге Закон 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектына**

# АҢЛАТМА

«Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проекты Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү һәм аны үстерү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру максатларында эшләнгән.

Закон проекты салым салуның гадиләштерелгән «Керемнәр – чыгымнар» системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен икътисадый эшчәнлекнең

эшкәртү җитештерүе;

электр энергиясе, газ һәм су җитештерү һәм бүлү;

төзелеш төрләре буенча 5% күләмендә салым ташламаларының гамәлдә булуын бер елга, 2026 елның 1 гыйнварына кадәр озайтуны күздә тота.

---

**«Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

---

**«Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектын**

# ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ

«Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә финанслауны таләп итми.

Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе мәгълүматы буенча 2023 елда 5% күләмендә салым ташламалары суммасы 0,3 млрд сум тәшкил иткән; аларны озайту чорында (2025 ел) салым преференцияләре суммасы якынча 0,4 млрд сум күләмендә бәяләнә.

---